КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 декабрь г.Казань № 1709

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантларын бирү конкурсларын үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантлары бирү конкурслары үткәрү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантларын бирү конкурсларын үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 78 нче; 2023 ел, 22 март, 324 нче; 2023 ел, 13 июль, 828 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерү өчен Татарстан Республикасы грантлары бирү конкурслары үткәрү буенча республика комиссиясе составына (алга таба – комиссия составы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан И.И.Шариповны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Кадыйров Тимур Рәфкать улын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасарын, «Татарстан халыкларының Дуслык йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директорын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сабирова Айгөл Азат кызын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасарын; |

Ирина Алексеевна Александровскаяның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Россия традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту комиссиясе рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Римма Хәмид кызы Гыйльмиеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мактаулы әгъзасы, «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең социаль-мәдәни эшчәнлек һәм педагогика кафедрасы профессоры (килешү буенча)»;

Мария Викторовна Крюкованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Татарстан яшьләре» Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, «Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы директоры (килешү буенча)»;

Тимур Җәүдәт улы Сөләймановның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасының «Движение первых» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисе (килешү буенча)»;

Данис Фәнис улы Шакировның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)».

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карары белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 7 апрель, 218 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карары белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 14 май, 358 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карары белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 15 апрель, 293 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 11 апрель, 274 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 3 апрель, 387 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруда катнашучы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның республика реестры турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1035 нче карарының үз көчен югалтуын тану хакында» 2023 ел, 13 июль, 828 нче карарының 2 пункты.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин